АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2024 п.г.т. Алексеевское № 253

**Алексеевск муниципаль районының Алексеевск муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставының XVI бүлегенә ярашлы рәвештә

**Алексеевск муниципаль район Советы карар бирде:**

1. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск район Советының «Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын беренче укылышта кабул итәргә (алга таба – Карар проекты) (1 нче кушымта).

Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

2. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибен һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуын расларга. (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында: https://alekseevskiy.tatarstan.ru/resheniya-soveta-alekseevskogo-munitsipalnogo.htm адресы буенча урнаштырырга.

4. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими депутат комиссиясенә (Ю.И. Тюкарев) проектка кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карауны йөкләргә.

5. Алексеевск муниципаль районы Советы депутатларының карар проектына тәкъдимнәре төзәтмәләр рәвешендә комиссиягә 2024 елның 16 маена кадәр кертелә дип билгеләргә.

6. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре комиссиягә язма рәвештә Ф.И.А., туган елы, авторның адресы күрсәтелеп, штб. Алексеевск, Совет мәйданы, 3 нче йорт адресы буенча җибәрелә, дип билгеләргә.

7. Алексеевск муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча җәмәгать тыңлауларын 2024 елның 17 маена 11-00 сәгатьтә муниципаль район Советының утырышлар залында үткәрергә.

Җәмәгать тыңлаулары Алексеевск муниципаль районында, Алексеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 194 номерлы карары белән расланган, җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибенә ярашлы рәвештә үткәрелә.

8. Комиссиягә район Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2024 елның 22 маена кадәр район Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

10. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы район Советының
18.04.2024 ел, № 253
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1. 6 нчы статьяда:**
**- 1 нче өлешнең 27 нче пунктында** сүзләрне «муниципаль район территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» төшереп калдырырга;
**- 1 өлешнең 32 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«32) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;
**- 1 өлешнең 33 пунктын** сүзләр белән тулыландырырга «, шулай ук рекреацион максатларда су объектларын куллану кагыйдәләре;»;
**- 1 нче өлешне** түбәндәге эчтәлектәге 40 нчы пункт белән тулыландырырга: «40) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерү оештыру.»;

**2. 7 статьясының 1 өлеше 16 пунктында** сүзләрне «муниципаль район территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» төшереп калдырырга;

**3. 14 нче статьяның 3 нче өлешендәге икенче абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль закон белән билгеләнгән очракларда муниципаль сайлаулар җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) яки суд тарафыннан билгеләнә.»;

**4. 31 нче статьяда:**
**- 3 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;
**- 3 өлешнең 2 пунктының б пунктчасында** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

- **3 өлешнең 2 пунктының б пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;
- **7 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **8 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**5. 35 нче статьяда:**
- **1 өлешнең 29 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«29) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;
**1 нче өлешнең 17 нче пунктын** төшереп калдырырга;

**6. 41 нче статьяның 2 нче өлешендә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**7. 43 нче статьяның 1 нче өлешендә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**8. 46 нчы статьяның 5 нче өлешендә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**9. 47 нчы статьяда:**
- **1 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **3 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;
- **4 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **5 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **6 нчы өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **7 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **10 нчы өлешнең 1 нче пунктында** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- **13 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**10. 48 нче статьяда:**
- **1 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләре белән алыштырырга;
- **3 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

- **4 нче өлештә** слова «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**11. 50 нче статьяда:**
**- 1 нче өлештә:**
**-пункт 1 не** «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;
**- пункт 2** дә «яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматны күрсәтүне яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтүне» сүзләре белән алыштырырга;
**- 2 нче өлешне** «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

**12. 53 нче статьяда:**
**- 1 өлешнең 3 пунктын** түбәндәге эчтәлектәге яңа абзац белән тулыландырырга:
«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклый һәм мондый зыянны муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата бетерүне оештыра;";
**1 өлешнең 6 пунктының бишенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;";
**- 3 өлешнең тугызынчы абзацында** «муниципаль район территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;
**- 3 өлешнең унынчы абзацын** төшереп калдырырга;
**- 3 өлешнең унберенче абзацын сүзләр белән тулыландырырга «, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләрен;»;**

**13. 56 статьяның 7 өлешендә** «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга;
**14. 59 нчы статьяда:**
**- 2 өлешнең 2 пунктында** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 3 өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**15. IX бүлекне** үз көчен югалткан дип танырга.

**16. 83 нче статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«83 нче статья.Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе.

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасының «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яки Алексеевск районының «Заря» газетасында , ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-47500 бирелгән 30.11.2011 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр олкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор);

2)«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы«Алексеевск муниципаль районы » муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру https://alekseevskiy.tatarstan.ru/.

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына гражданнарның керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу түбәндәге адреслар буенча урнашкан пунктлар эшли:

-шәһәр тибындагы бистә Алексеевск, Совет мәйданы, 2 нче йорт, Татарстан Республикасы Алексеевск районы КФҮ ДБУ бинасы;

-шәһәр тибындагы бистә Алексеевск, Казаков урамы, 12 йорт, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ бинасы.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә игълан ителә.

5. Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр

басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә, китерелә «Татарстан Республикасы» Алексеевск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми мәгълүматка кадәр.

**16. 86 нчы статьяда:**
**- 1 нче өлештә** «район Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 3 нче өлештә** «район Сайлау комиссиясе аппаратын» сүзләрен төшереп калдырырга;

**17. 87 нче статьяда:**
**- 2 нче өлештә** «район Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 2 нче өлештә** «район Сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

**18. 90 нчы статьяда:**
**- 1 өлешнең 5 пунктында** «, район Сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 3 өлешнең 4 пунктында** «, районның Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

**19. 91 нче статьяда:**
**-1 өлешнең 1 пунктындагы пунктчада** «, район Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 1 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 1 өлешнең 2 пунктының б пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 1 өлешнең 4 пунктында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;
**1 өлешнең 6 пунктында** «район Сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 1 нче өлешенең 9 нчы пунктында** «район Сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 4 нче өлештә** «район сайлау комиссиясе аппаратын» сүзләрен төшереп калдырырга;

**20. 92 нче статьяда:**
**- 1 нче өлештә** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга;
**-4 нче өлештә** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратын,» сүзләрен төшереп калдырырга;
**5 нче өлештә** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

**- 10 нчы өлешнең 3 нче пунктында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрне төшереп калдырырга;

**21. 94 нче статьяда:**

- **5 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентына» дигән сүзләрне«Татарстан Республикасы Рәисенә» дигән сүзләр белән алыштырырга;
- **7 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» дигән сүзләрне«Татарстан Республикасы Рәисен» дигән сүзләр белән алыштырырга;
- **8 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президенты» дигән сүзләрне«Татарстан Республикасы Рәисе» дигән сүзләр белән алыштырырга;

**22. 98 нче статьяның 4 нче өлешендә:**

- «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының », сүзләрен төшереп калдырырга;

**23. 106 нчы статьяның 7 нче өлешендәге өченче абзацта** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга.

**Совет рәисе С.А. Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы район Советының
18.04.2024 ел, № 253
карарына 2 нче кушымта

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ҺӘМ ГРАЖДАННАРНЫҢ АНЫ ТИКШЕРҮДӘ КАТНАШУЫ ТУРЫНДА» КАРАРГА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы аппаратына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск шәһәр тибындагы бистәсе, Совет мәйданы, 3 йорт, язма рәвештә.

2. Тәкъдимнәр эш көннәрендә «Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар тексты рәсми рәвештә урнаштырылганнан соң 8 дән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск шәһәр тибындагы бистәсе, Совет мәйданы, 3 йорт, шәхсән яки почта аша (конвертта «Уставны тикшерү»билгесе белән).

**Совет Рәисе,**
**муниципаль район башлыгы** **С. А. Демидов**